ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» 06 2021 ел № 161

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында 2021 елгы авыл хуҗалыгы минкросанын алуны әзерләү һәм үткәрү буенча ведомствоара комиссия төзү турында**

«Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 108-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләүне һәм үткәрүне оештыру турында» 2020 елның 30 декабрендәге 1265 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә 2021 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм үткәрү буенча җирле үзидарә органнарының килештерелгән гамәлләрен координацияләү һәм тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм үткәрү буенча ведомствоара комиссия төзергә (килештерү буенча).
2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм үткәрү буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмәне һәм аның составын (1 нче, 2 нче кушымталар) расларга.
3. Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

билгеләнгән вакытка Дәүләт статистикасының Алабуга шәһәрендәге (Балтач шәһәр тибындагы поселогында) бүлегенә, тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә яшәүче җирдән файдаланучылар турында, аларга беркетелгән җир мәйданы һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алу күрсәткечләре нигезендә 2021 елның 1 гыйнварына актуальләштерелгән терлекләрнең баш санын күрсәтеп, белешмәләр тапшыруны тәэмин итәргә;

Дәүләт статистикасының Алабуга шәһәрендәге (Балтач шәһәр тибындагы поселогында) бүлегенә тиешле муниципаль берәмлекләр территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарын авыл хуҗалыгы микросанын алу объектлары турында белешмәләр җыюда,шулай ук авыл хуҗалыгы микросанын алу объектлары турында белешмәләр җыючы затларны укыту һәм аларның эше өчен, авыл

хуҗалыгы исәбен алу кәгазьләрен һәм башка документларын саклау яраклы урыннар сайлауда ярдәм күрсәтергә;

4. «Татмедиа» АҖ филиалы «Хезмэт» газетасы редакциясенә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Кайтаваз» телерадиокомпаниясе» МБУ 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләүне һәм үткәрүне мәгълүмати яктыртуны гамәлгә ашырырга, авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм үткәрү мәсьәләләре буенча мәгълүмати-аңлату эшләрен гамәлгә ашырырга тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми baltasi.tatarstan.ru сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Балтач муниципаль районы
башлыгы

Р. Р. Нотфуллин

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы башлыгының
2021 елның 30 июнь
161 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында 2021 елгы авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм үткәрү буенча ведомствоара комиссия турында НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Балтач муниципаль районында 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм үткәрү буенча ведомствоара комиссия (алга таба - ведомствоара комиссия) җирле үзидарә органнарының килештерелгән гамәлләрен координацияләү һәм тәэмин итү, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм үткәрү мәсьәләләрен оператив хәл итү өчен төзелде.

2. Ведомствоара комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе, «Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 108-ФЗ номерлы Федераль закон, «2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны оештыру турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 29 августындагы 1315 номерлы карары, «Татарстан Республикасы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләүне һәм үткәрүне оештыру турында» 2020 елның 30 декабрендәге 1265 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Президенты указлары һәм боерыклары, Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары, Балтач муниципаль районының норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм үткәрү комиссиясе турында нигезләмә, шулай ук әлеге нигезләмә нигезендә эш итә.

3. Ведомствоара комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

Балтач муниципаль районы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм үткәрү буенча җирле үзидарә органнарының килештерелгән гамәлләрен тәэмин итү.

авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләүгә һәм уздыруга бәйле мәсьәләләрне оператив хәл итү.

авыл хуҗалыгы микросанын алу турында район халкы арасында мәгълүмати-аңлату эшләрен алып бару.

4. Ведомствоара комиссия үзенә йөкләнгән бурычларны гамәлгә ашыру өчен түбәндәге мәсьәләләрне карый:

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарының, җирле үзидарә органнарының авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү, үткәрү, аның материалларын

эшкәртү һәм авыл хуҗалыгы исәбен алуның нәтиҗәләрен рәсми бастырып чыгару барышы турында үзара хезмәттәшлек;

авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм үткәрү;

авыл хуҗалыгы исәбен алуны үткәрү эшенә төрле оештыру-хокукый формадагы оешмаларны җәлеп итү.

5. Ведомствоара комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

үз утырышларында Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Балтач муниципаль районы территориясендә җирле үзидарә органнары вәкилләрен 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм үткәрү барышы турында тыңларга;

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарыннан, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм үткәрү мәсьәләләре буенча кирәкле материалларны билгеләнгән тәртиптә соратып алырга;

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, Балтач муниципаль районындагы Татарстан Республикасы буенча җирле үзидарә органнарына авыл хуҗалыгын микросанын алуны әзерләү һәм үткәрү мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр җибәрергә;

ведомствоара комиссия эшенә Балтач муниципаль районы буенча федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары вәкилләрен, фәнни, иҗтимагый берләшмәләр һәм дини оешмалар вәкилләрен, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларын җәлеп итәргә;

ведомствоара комиссиягә йөкләнгән бурычларны хәл итүгә бәйле мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр эшләү өчен эшче төркемнәр төзергә.

6. Ведомствоара комиссия составы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы тарафыннан раслана.

Ведомствоара комиссия рәистән, аның урынбасарыннан, ведомствоара комиссия әгъзаларыннан һәм секретарьдан тора.

Рәис ведомствоара комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, Комиссия составын төгәлләштерү һәм яңарту турында тәкъдимнәр кертә, аның утырышларын алып бара, ведомствоара комиссиянең эш планнарын раслый.

Ведомствоара комиссия рәисе булмаганда яисә аның йөкләмәсе буенча рәис вазыйфаларын ведомствоара комиссия рәисе урынбасары башкара.

7. Ведомствоара комиссия утырышлары кирәк булган саен, әмма ярты елга кимендә бер тапкыр уздырыла. Ведомствоара комиссия утырышларын аудио - һәм видеоконференция режимында тиешле чыганакларга яздырып үткәрергә мөмкин.

Ведомствоара комиссия рәисе (ул булмаганда аның урынбасары) мәсьәләләрне карау тәртибен билгели, ведомствоара комиссия утырышының көн тәртибен раслый, ведомствоара комиссия составын үзгәртү турында тәкъдимнәр кертә.

Ведомствоара комиссия утырышларының көн тәртибе, авыл хуҗалыгы исәбен алуны үткәрү буенча эш планы нигезендә, Дәүләт статистикасының Алабуга шәһәрендәге (Балтач шәһәр тибындагы поселогында) бүлеге тәкъдимнәре нигезендә төзелә.

Комиссия әгъзалары комиссия утырышларында шәхсән катнашалар һәм

ведомствоара комиссия утырышында карала торган мәсьәләләр буенча фикер алышканда тигез хокукларга ия.

Әгәр утырышта комиссия әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, ведомствоара комиссия утырышы тулы хокуклы дип санала.

Ведомствоара комиссия әгъзалары һәм чакырылган затлар докладлар һәм өстәмә докладлар белән чыгыш ясый, фикер алышуларда катнаша, тәкъдимнәр кертә, тикшерелә торган сорауларның асылы буенча белешмәләр бирә алалар.

8. Ведомствоара комиссия карарлары утырышта катнашучы ведомствоара комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, рәиснең (ул булмаганда - аның урынбасары) тавышы хәлиткеч булып тора.

Комиссия карарлары ведомствоара комиссия рәисе (ул булмаган очракта, утырышта рәислек итүче урынбасары) тарафыннан имзалана торган беркетмәләр белән рәсмиләштерелә.

9. Ведомствоара комиссия эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итү Дәүләт статистикасының Алабуга шәһәрендәге (Балтач шәһәр тибындагы поселогында) бүлеге тарафыннан башкарыла.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы башлыгының
2021 елның 30 июнь
161 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында 2021 елгы авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм үткәрү буенча ведомствоара комиссия составы**

| № т/б | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Вазыйфа |
|---|---|---|
| 1. | Нотфуллин Р. Р. | Балтач муниципаль районы башлыгы (комиссия рәисе) |
| 2. | Хәйретдинов А. Ф. | Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе (рәис урынбасары) |
| 3. | Гәниева Р. Р. | Дәүләт статистикасының Алабуга шәһәрендәге (Балтач шәһәр тибындагы поселогында) бүлегенең баш белгече-эксперты - комиссия секретаре (килешү буенча) |
| *Комиссия әгъзалары:* | | |
| 4. | Борһанов Ш. Ф. | район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге җитәкчесенең урынбасары |
| 5. | Гарәфиев Р. Ф. | «Балтач торак-коммуналь хуҗалыгының күптармаклы җитештерү предприятиесе» акционер җәмгыяте директоры (килешү буенча) |
| 6. | Зәкиев В. М. | «Татмедиа» АҖ филиалы «Хезмәт» район газетасы баш мөхәррире-директоры (килешү буенча) |
| 7. | Зарипова Д. В. | Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Балтач һәм Кукмара районнары буенча муниципальара бүлегенең баш белгече-эксперты (килешү буенча) |
| 8. | Ильясов Р. М. | Балтач муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе |
| 9. | Исрафилов А. З. | «Балтач район дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ җитәкчесе (килешү буенча) |
| 10. | Маннапова А. Г. | Балтач муниципаль районында авыл хуҗалыгы микросанын алу буенча вәкаләтле вәкил урынбасары (килешү буенча). |
| 11. | Маннапова Г. С. | Балтач муниципаль районының «Кайтаваз» ТРК МБУ директоры (килешү буенча) |

| | | |
|---|---|---|
| 12. | Мөхәммәтҗанова Р. Х. | Балтач район Советы аппараты җитәкчесе |
| 13. | Муллагалиева Э. Ф. | Балтач район Советының оештыру бүлеге җитәкчесе |
| 14 | Муллагалиева Г. Ә | Балтач муниципаль районында авыл хуҗалыгы микросанын алу буенча вәкаләтле вәкил (килешү буенча). |
| 15. | Нәбиуллин Ф. Р. | Балтач районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы (килешү буенча) |
| 16. | Сабирҗанов Н.Н. | Балтач муниципаль районы башлыгы урынбасары |
| 17. | Усманов И. К. | Россия Эчке эшләр министрлыгының Балтач районы буенча бүлеге начальнигы (килешү буенча) |
| 18. | Хафизов Р. Р. | Россия Эчке эшләр министрлыгының Балтач районы буенча бүлегенең миграция мәсьәләләре буенча бүлекчәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| 19. | Фәтхетдинов И. М. | Балтач муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе |
| 20. | Фатыйхов Р. С. | Балтач район башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы |